ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08 февраль 2017 ел № 587

Гражданнарны аз керемле дип тану максатында аларның керем күләменең һәм мөлкәт бәясенең чик кыйммәтен раслау турында

Гражданнарны аз керемле дип тану һәм аларга муниципаль торак фондындагы торак биналарны социаль наем килешүе буенча бирү максатында, Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем килешүләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ санлы Законы һәм шәһәр Уставының 41 маддәсе нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. 2017 елга гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килүче керем күләменең һәм гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт бәясенең түбәндәге чик кыйммәтләрен билгеләргә:

1) гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килүче керемнең чик кыйммәте – 8 185 сум;

2) гаилә әгъзаларының яки ялгыз яшәүче гражданның милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт бәясенең чик кыйммәте:

- ялгыз яшәүче граждан өчен – 631 422 сум;
- ике кешелек гаилә өчен – 1 262 844 сум;
- өч кешелек гаилә өчен – 1 894 266 сум;
- дүрт кешелек гаилә өчен – 2 525 688 сум;
- биш кешелек гаилә өчен – 3 157 110 сум;
- алты кешелек гаилә өчен – 3 788 532 сум;
- жиде кешелек гаилә өчен – 4 419 954 сум;
- сигез кешелек гаилә өчен – 5 051 376 сум.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ГОРОДА НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ * ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Управление делопроизводством
Эш кәгазьләрен алып бару идарәсе

Р.Ә. Абдуллин